# КАРАР

## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Родники торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

10.10.2023 г. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 10 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Родники торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- юлларны төзекләндерү, ремонтлау һәм карап тоту.
- урамнарны яктыртуны карап тору (лампаларны алыштыру);
-«Ивашан Лисьма» чишмәсенә чыгу күперен төзекләндерү, ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 111 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 72 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 72 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлегендәге Родники авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының « Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Родники авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы

хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- юлларны төзекләндерү, ремонтлау һәм карап тоту.
- урамнарны яктыртуны карап тору (лампаларны алыштыру);
-«Ивашан Лисьма» чишмәсенә чыгу күперен төзекләндерү, ремонтлау.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен,Родники авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге башлыгы Е.А. Яковлева